| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>ЯР БУЕ МОРКВАШЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 23.06.2023 | 35-211 |

с. Набережные Моркваши

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Яр Буе Моркваша авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик зат вафат булган көннән яисә граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан ителгән көннән соң өч еллык срок узу, әгәр дә варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас итеп калдырырга хокуксыз яисә барлык варислар мираска читләштерелгән булса, яки варисларның берсе дә мирасны кабул итмәсә, яки барлык варислар мирастан баш тартса һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын әйтмәсә;

2) салым түләүченең - гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы;

3) салым салу объекты булган мөлкәткә милек хокукы туктатылган көннән өч ел вакыт узгач;

4) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узгач.

2. Яр Буе Морквашы авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип

тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2022 елның 19 декабрендәге 29-172 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х.Гаязов